Республика Татарстан
Исполнительный комитет Рангазарского сельского поселения Сармановского муниципального района

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлеге башкарма комитеты

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

25 декабрь 2024 ел № 16

Белешмә (өземтә) бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтү
административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында, «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетынын 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына таянып, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районыны Рангазар авыл җирлеге башкарма комитеты, КАРАР БИРӘ:

1. Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең кушымтада бирелә торган административ регламентын расларга;
2. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Рангазар авыл җирлеге башкарма комитетының «Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 18 июнендә кабул ителгән 12 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» урнаштыру юлы белән http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында интернет-телекоммуникация челтәрендә https://sarmanovo.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Сарман муниципаль районы
Рангазар авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Р.Н.Кыямов